КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 17 декабрь г.Казань № 1246

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Яңа инвестиция проектларын тормышка ашыру өчен кирәкле инфраструктура объектларын төзү чыгымнарын каплау өчен юридик затларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 3 ноябрь, 1041 нче карары белән расланган Яңа инвестиция проектларын тормышка ашыру өчен кирәкле инфраструктура объектларын төзү чыгымнарын каплау өчен юридик затларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Яңа инвестиция проектларын тормышка ашыру өчен кирәкле инфраструктура объектларын төзү чыгымнарын каплау өчен юридик затларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 3 ноябрь, 1041 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 15 декабрь, 1236 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Яңа инвестиция проектларын тормышка ашыру өчен кирәкле инфраструктура объектларын төзү чыгымнарын каплау өчен юридик затларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.6 пунктның икенче абзацында «төзүгә» сүзен «булдыруга» сүзенә алмаштырырга;

2.4 пунктта:

унберенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«сайлап алуда катнашучының бу Тәртипнең 1.6 пунктында күрсәтелгән юнәлешләр буенча факттагы чыгымнарын раслый торган документлар күчермәләре (юридик затлар һәм (яки) индивидуаль эшмәкәрләр белән эшләр башкаруга һәм хезмәт күрсәтүләргә шартнамәләр күчермәләре, КС-2 формасы буенча башкарылган эшләрне кабул итү турында актлар күчермәләре, КС-3 формасы буенча башкарылган эшләр һәм чыгымнар кыйммәте турында белешмә кәгазьләре күчермәләре, КС-11 формасы буенча төзелеше тәмамланган объектларны кабул итү актлары күчермәләре, инфраструктура объектларын булдыру өчен төзелеше тәмамланмыйча сатып алынган объектларны сатып алу-сату шартнамәләре күчермәләре);»;

унтугызынчы абзацка «(булганда)» сүзләрен өстәргә;

егерменче абзацка «(булганда)» сүзләрен өстәргә;

егерме беренче абзацка «(булганда)» сүзләрен өстәргә;

егерме икенче абзацка «(булганда)» сүзләрен өстәргә;

егерме өченче абзацка «(булганда)» сүзләрен өстәргә;

3.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. Субсидия күләме (С) бу Тәртипнең 2.4 пунктындагы егерме дүртенче абзацында күрсәтелгән исәп-хисап белешмә кәгазе һәм бу Тәртипнең 2.4 пунктындагы унберенче, уникенче, унбишенче, уналтынчы, унтугызынчы, егерме беренче абзацларында күрсәтелгән, бу Тәртипнең 1.6 пунктында күрсәтелгән юнәлешләр буенча өстәлгән кыйммәткә салымсыз факттагы чыгымнарны раслый торган документлар нигезендә билгеләнә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$С = З_1 + З_2 + З_3 + З_4,$$

монда:

$З_1$ – өстәлгән кыйммәткә салымны исәпкә алмыйча, инфраструктура объектларын булдыруга фактта тотылган чыгымнар;

$З_2$ – өстәлгән кыйммәткә салымны исәпкә алмыйча, инфраструктура объектларын модернизацияләүгә һәм (яки) реконструкцияләүгә фактта тотылган чыгымнар;

$З_3$ – өстәлгән кыйммәткә салымны исәпкә алмыйча, технологик тоташтыруга фактта тотылган чыгымнар;

$З_4$ – өстәлгән кыйммәткә салымны исәпкә алмыйча, инфраструктура объектлары буенча проект-тикшеренү эшләрен һәм проект-смета документациясен әзерләү эшләрен үткәрү хезмәтләре өчен түләүгә фактта тотылган чыгымнар.

Бу Тәртипнең 1.6 пунктында күрсәтелгән юнәлешләр буенча фактта тотылган чыгымнарны, инфраструктура объектларын төзүнең смета кыйммәтен билгеләү дөреслеген тикшерү өлешендә проект документациясенә дәүләт экспертизасының уңай бәяләмәсендә күрсәтелгән смета кыйммәте күләмен арттырганда, Субсидия

күләмен исәпләп чыгарганда проект документациясенә дәүләт экспертизасының уңай бәяләмәсендә күрсәтелгән сумма исәпкә алына.

Шул ук вакытта Субсидия күләме бу Тәртипнең 1.5 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен билгеләнгән тәртиптә Министрлыкка җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитларыннан артмаска тиеш.».

2. Бу карарның гамәле 2021 елның 8 ноябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин